ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 1375 «07» 11 2016 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы территориясендә
даими рәвештә пассажирлар йөртүнең
һәм багаж ташуның муниципаль
маршрутлары буенча автомобиль
транспортында даими рәвештә
пассажирлар йөртүне һәм багаж
ташуны планлаштыру документын
әзерләү тәртибе турында

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 4 өлеше, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты нигезендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыру максатында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны планлаштыру документын әзерләү тәртибен расларга (кушымта).

2. Әлеге карарны рәсми матбугат басмасында – «Нократ «Вятка» газетасында,» Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми http://pravo.tatarstan.ru порталында һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.М. Дәрҗемановка йөкләргә.

Җитәкче И.Э. Фәттахов

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының
07.11 2016 № 1375 карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны планлаштыру документларын әзерләү тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уставы» муниципаль берәмлеге нигезендә эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны планлаштыру документын (алга таба – планлаштыру документы) әзерләгәндә үтәлергә тиешле төп таләпләрне билгели.

2. Планлаштыру документына түбәндәге төп бүлекләр булырга тиеш:

- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында һәм җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә озак сроклы сәясәтнең гомуми нигезләмәләре;

- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның агымдагы торышы һәм проблемалары;

- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны үстерү чаралары.

3. Халыкны даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны планлаштыру документын әзерләү Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестры нигезендә гамәлгә ашырыла.

4. Планлаштыру документы кимендә өч ел вакытка әзерләнә.

5. Планлаштыру документында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж йөртүнең муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны үстерү чаралары исемлеге билгеләнә.

6. Планлаштыру документында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны үстерү чараларын үтәү сроклары билгеләнә һәм җаваплы башкаручы күрсәтелә.

7. Планлаштыру документын әзерләү барышында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә даими муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар йөртүче юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның тәкъдимнәре исәпкә алынырга мөмкин.

8. Планлаштыру документы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана һәм массакүләм мәгълүмат чараларында, шулай ук Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми интернет-сайтында рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

Җитәкче урынбасары И.М.Дәрҗеманов